**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

**2023 елның 20 ноябре** **3648 номер**

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында» 2016 елның 10 августындагы 1814 номерлы карарга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрендә муниципаль торак контролен оештыру һәм гамәлгә ашыру максатларында «Россия Федерациясе торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 02 декабрендәге 390-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә **карар бирәм**:

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында» 2016 елның 10 августындагы 1814 номерлы Башкарма комитет карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә, 3.3 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Планлы тикшерүне еллык планлы тикшерүләр үткәрү планына кертү өчен нигез булып бер ел узгач

-торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш кооперативы яки күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы тарафыннан күрсәтелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыру башлану турында Дәүләт торак күзәтчелеге органына тапшырылган хәбәрнамәгә ярашлы рәвештә эшчәнлекне гамәлгә ашыра башлау тора;

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.О.Солягинга йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**